| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е                    К А Р А Р

2019 елның «04» октябре                    №1433

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашырырга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген раслау турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибе турында» 1999 елның 21 августындагы 46 номерлы Лениногорск район Советы карары нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашырырга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген расларга.

2. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче                    Н.Р. Залаков

И.Р.Хәйбрахманов
5-44-72

Расланды

“Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән

04 октябрь, 2019 ел, № 1433

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашырырга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге

| № п/п | җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төре | Тиешле муниципаль контроль төрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы исеме | тиешле җирле үзидарә органына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирү турында норматив хокукый акт реквизитлары |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Муниципаль берәмлек территориясендә җирләрдән файдалануны муниципаль җир контроле | «Милек һәм җир мөнәсәбәтләоe палатасы» МКУ | Җир кодексының 72 ст.; Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «131 номерлы Федераль законның 35 ст., 15 ст.» |
| 2 | Мөлкәтнең билгеләнеше һәм сакланышы буенча муниципаль контроль | «Милек һәм җир мөнәсәбәтләоe палатасы» МКУ | Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 295 ст. |